Дәреснең темасы. “Сыйфат фигыль”

Рус мәктәпләренең 7нче сыйныф татар төркемнәре өчен

Дәреснең тибы. Уку мәсьәләсе кую һәм чишү дәресе. (Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе буенча)

Максатлар. 1. Укучыларга сыйфат фигыльнең нәрсә белдерүен аңларга, аның җөмләдә нинди җөмлә кисәге булуын ачыкларга ярдәм итү. Сыйфат фигыльнең өч заманда килә алуын укучылар аңына җиткерергә булышу. Сыйфат фигыльләр кулланып җөмләләр төзү, күнегүләр эшләү. 2. Ата - анага карата кадер - хөрмәт хисләре тәрбияләргә ярдәм итү. 3. Укучыларның мөстәкыйль фикерләвен, сөйләм телен, язу культурасын үстерү. Җиһазлар. Тактада язылган җөмләләр, мәкальләр.

Дәрес планы.

1. Дәресне оештыру.

Н.Өй эшен тикшерү. Өй эше - хикәя, боерык, шарт фигыльләр кулланып язылган

“Кышкы урманада” дигән хикәя.

Өй эше башта төркемнәрдә тикшерелә, шуннан һәр төркемнән бер укучы хикәясен укый. Укучылар үзләре кулланган шарт, хикәя, боерык фигыльләрне әйтәләр.

(Укучылыр үзләренең эшләренә билге куялар)

Ш.Уку мәсьәләсе кую.

Укытучы. Укучылар, без сезнең белән бүгенге дәрестә фигыль төркемнәрен өйрәнүне дәвам иттерәбез.

IV. Уку мәсьәләсен чишү.

1нче бирем.

Мин тактага ике мәкаль язып куйдым. Менә алар:

Бала чактан кергән гадәт чыкмый. Баласы өчен ана арыслан утка кергән. УКЫТУЧЫ. Укучылар, 2нче җөмләдәге “кергән” сүзе турында*нәрсәләр әйтә аласыз? (Укучылар төркемнәрдә эшлиләр, һәр төркемнән бер укучы җавап бирә).

Көтелгән җавап. “Кергән” сүзе - бу җөмләнең хәбәре. Ул сыйныф турында хикәяләп хәбәр итә. Шуңа күрә' ул - хикәя фигыль. Үткән заманда үтәлә торган эш турында хәбәр итә. Соравы - нишләгән? Үткән заман хикәя фигыль.

2нче бирем.

Укытучы. Дөрес, укучылар, “кергән” сүзе җөмлә ахырында килгәндә, хикәя фигыль була. Хәзер беренче җөмләдәге “кергән” сүзен тикшерик. Бу сүз турында нәрсәләр әйтә аласыз? Ул нинди сүз төркеменә охшаган?

(Укучылар төркемнәрдә эшлиләр, һәр төркемнән 1 укучы җавап бирә)

Укучылар җавабы.

- Ул нишләгән? соравына җавап бирә.
- Ул эшне белдерә, ул фигыльгә охшаган.
- Ул нинди? соравына җавап бирә.
- Ул исемгә ияреп килгән, шулай булгач “гадәт” сүзенең билгесен белдерә.

Знче бирем.

Укытучы. Бу сүз нинди җөмлә кисәге булыр?

Укучылар җавабы. Ул җөмләдә аергыч булыр, чөнки “кергән” сүзе исемне ачыклый. Укытучы. Укучылар, әйдәгез инде хәзер бөтен әйткәннәрдән чыгып, нәтиҗә ясыйк. Без өйрәнгән фигыльгә нинди исем кушарбыз? һәм ул нәрсәне белдерә?

Укучылар җавабы.

- Бер сүз бер үк вакытта сыйфат һәм фигыль мәгънәләренә ия булды, шуңа күрә аңа сыйфат фигыль дип исем кушыйк.
- Ул предметның билгесен аның эше, хәрәкәте буенча белдерә.

(Укучылыр үзләренә билге куялар).

4нче бирем.

Укытучы. Ә хәзер, укучылар, түбәндәге җөмләләрдән сыйфат фигыльләрне табыйк. Алар нәрсә белән аерылалар?

1. Ата - анасын тыңлаган бала адәм булган, тыңламаган бала әрәм булган.
2. Ата - анасын зурлаучы баланы кешеләр дә зурлый.
3. Кайтыр йортың, көтәр кешең булсын.

Укытучы: Беренче җөмләдәге сыйфат фигыльгә сорау куйыйк. Ул кайчан эшләнгән эшне белдерә?

(Төркемнәр уйлыйлар, һәр төркемнән бер уку^ы җавап бирә).

Укучылар җавабы.

- Беренче җөмләдә сыйфат фигыль нишләгән? дигән сорауга җавап бирә.
- Сөйләүче сөйләп торган вакыттан алда эшләгән эшне белдерә.
- Үткән заманны белдерә.

5нче бирем.

Укытучы. Дөрес әйттегез. Икенче җөмләдә сыйфат фигыль кайчан эшләнгән эшне

белдерә.

Укучылар. Хәзерге заманда эшләнгән эшне белдерә һәм нишләүче? дигән сорауга җавап бирә.

Укытучы. Дөрес. Өченче җөмләдә сыйфат фитәть кайчан эшләнәчәк эшне белдерә. Укучылар.

- Киләчәк заманда.